Республика Татарстан
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КИЛЬДЕБЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422071, Республика Татарстан,
с. Кильдебяк, ул. Кооперативная, 20а
тел. 45-5-50

Татарстан Республикасы
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КИЛДЕБЭК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422071, Татарстан Республикасы,
Килдебәк авылы, Кооператив урамы, 20а йорт
тел. 45-5-50

Kilb.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

14.09.2018 | №34

Килдебәк авыл җирлеге Башкарма комитетының
2016 елның 30 сентябрендә 38 нче номер белән расланган
"Килдебәк авыл җирлеге Башкарма комитеты
тарафыннан алдан төзелгән территорияләрне үстерү
өчен җир кишәрлеге бирү" муниципаль хезмәте күрсәтү
Административ регламентын раслау турында" карарына
үзгәрешләр кертү турында

ТР Саба районы прокуратурасының 2018 елның 10 сентябрендәге 02-01-20-18 нче номерлы хаты нигезендә, Килдебәк авыл җирлеге башкарма комитеты
КАРАР ИТТЕ:

1 Килдебәк авыл җирлеге Башкарма комитетының 2016 елның 30 сентябрендә 38 нче номер белән расланган "Килдебәк авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан алдан төзелгән территорияләрне үстерүөчен җир кишәрлеге бирү" муниципаль хезмәте күрсәтү Административ регламентын раслау турында" карарының 5.1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 8 һәм 9 пунктчалар белән тулыландырырга:

"8) дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирүнең срогы яки тәртибе бозылу;

9) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору, әгәр туктатып тору федераль законнар һәм аларга яраклаштырып кабул ителгән Рәсәй Федерациясенең башка норматив-хокукый актлары, Рәсәй Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актлары һәм законнары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган булса. Күрсәтелгән очракта, әгәр күпфункцияле үзәккә Федераль законның 16 нчы матдәсе, 1-3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә тулы күләмдә дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү функциясе йөкләнгән булса, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең гамәленә(гамәл кылмавына) һәм карарларына судка кадәр(судтан тыш) шикаять бирү мөмкин."

Килдебәк авыл җирлеге башлыгы: Н.Н.Загидуллин